СОВЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Красавина, д.40, с. Набережные Моркваши,
422594

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Красавин ур., 40 нче йорт, Яр Буе Моркваши авылы,
422594

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ | КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

08.11.2024 | с. Набережные Моркваши | 53-304

Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең
Яр буе Морквашы торак пункты территориясенең бер өлешендә үзара салым кертү
һәм аннан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставының 24 статьясына туры китереп,

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2024 елның 23 ноябренә Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Яр буе Морквашы торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнар арасында үзара салым акчасын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Яр буе Морквашы торак пункты территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 10000 сум күләмендә кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә сез риза булырсызмы:

- Яр буе Морквашы торак пункты Волгоград урамы чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Яр буе Морквашы авылы, Красавин урамы, 40 йорт адресы буенча (Башкарма комитет бинасы)11.00 сәгатьтә гражданнар җыенын үткәрергә.

4. Яр буе Морквашы авыл җирлегенең башкарма комитеты гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы И.Х. Гаязов